**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» март 2025 ел Күзкәй авылы № 4

«Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2024 елның 26 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге уставы нигезендә Башкарма комитет

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.8 пунктында «ризалыксыз» сүзен «килештерүдән башка» сүзләренә алыштырырга;

1.2. 3.1 пунктында «Автомобиль юллары өчен,» сүзләреннән соң «дүртенче һәм бишенче категорияле автомобиль юлларыннан һәм» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәми хокукый мәгълүмат порталында (http://www. pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Э.Р. Гәрәев